СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИЕКТАУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422701, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Высокая Гора , ул. Б.Красная, зд. 113 А

422701, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау авылы, Зур Кызыл, 113 А

тел./факс 8(84365) 7-47-79, 7-47-78e-mail: Vgor.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**17.12.2024г.** **№ 415**

## Биектау авыл җирлеге Советының 28.04.2018 елның 346 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясенең 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында «2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы карары нигезендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы үзидарәләр, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр», Биектау авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 28.04.2018 ел, № 346 Биектау авыл җирлеге Советы карарына (Советның 28.12.2018 ел, №468 карарлары редакциясендә) кертергә. 24.09.2018 № 425, 15.10.2020 № 12,13.10.2022 № 233, 24.11.2022 № 245, 28.06.2024 № 372) түбәндәге үзгәрешләр:

-1 пунктның 3 абзацында «13323 "санын" 13990 " санына алмаштырырга»;

-2 нче кушымтада «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге башлыгын акчалата бүләкләү күләмнәре» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Вазыйфа исеме | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|

| | |
|---|---|
| | 9 төркем |
| Авыл җирлеге башлыгы | 26 029 |

- 13 нче кушымтаның 2 пунктындагы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу дигәндә картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә җиткәч муниципаль хезмәттән азат ителү яки "иминият пенсияләре турында" 28.12.2013 N 400-ФЗ Федераль закон нигезендә һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы булганда инвалидлык буенча иминият пенсиясен билгеләү аңлашыла.

Бер мәртәбә бүләкләү түләнми:

- эштән азат ителгән вакытка дисциплинар җәзасы булган муниципаль хезмәткәргә;

- законнар нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү түләнгән муниципаль хезмәткәргә;

- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган хокук бозулар кылган өчен муниципаль хезмәттән азат ителгәннәр».

2.Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында: http//vysokaya-gora/tatarstan/ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы А. А. Хәбибуллин